# “ЧИШМӘ БАШЫ”

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының "Арча 6 нчы номерлы урта гомуми белем мәктәбе" муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесе

**Декабрь, 2024 нче ел** **Чыгарылыш №2**

## Нинди яңалыклар бар?

4 нче декабрьдә, "Тату сыйныф серләре" республика конкурсының мәктәп этабына йомгак ясалды.
5 нче А сыйныфының ата-аналар комитеты 1 урынны яулады. Алар әлеге конкурсның муниципаль этабында безнең мәктәп исеменнән чыгыш ясаячак. Сыйныф җитәкчесе: Миңнебаева Гөлназ Илшат кызы.



6 нчы декабрьдә, Казан Кремленең Вәкиллек корпусында Коррупциягә каршы юнәлештәге конкурста җиңүчеләрне бүләкләү тантанасы узды. Үзебезнең мәктәптән әлеге конкурста катнашып, Гран-при иясе булган 7 нче В сыйныфы укучысы Гаптелбәров Ранельне һәм 2 нче урынга лаек булган 5 нче А сыйныфы укучыларын котлыйбыз.
Афәрин!Аларга дипломнар һәм истәлекле бүләкләр тапшырылды.
Җитәкчеләре: Р. Ф. Сәйфетдинов, Г. И.Миннебаева
Без сезнең белән горурланабыз!



Арча муниципаль районының мобилизацияләнгән гражданнарына ярдәм итү максатыннан "Без сезнең белән" патриотик акциясе кысаларында "Игелекле хатлар" акциясе уза. Акция кысаларында укучылар солдатлар өчен хатлар яздылар, планнары һәм хыяллары турында сөйләделәр, солдатларга хезмәтләре өчен рәхмәт белдерделәр һәм үзләренең теләкләрен җиткерделәр.



## "Ел укытучысы"



16 нчы декабрьдә безнең мәктәп базасында "Ел укытучысы"конкурсының муниципаль этабына йомгак ясалды. Конкурс сынауларына "Дәрес фрагменты" һәм "Осталык дәресе"кергән иде.
"Педагогик дебют" номинациясендә физика укытучысы Фәттахова Айсылу Рамил кызы - 1 урын, инглиз теле укытучысы Сабирова Эмилия Илдар кызы-3 урын, "Ел укытучысы" номинациясендә башлангыч сыйныф укытучысы Шакирова Фәридә Фәрит кызы-3 урын, "Иң яхшы татар теле һәм әдәбияты укытучысы" номинациясендә татар теле һәм әдәбияты укытучысы Муллагалиева Гүзәл Нургали кызы 1 урын яуладылар!🏆
Сезне конкурста лаеклы җиңүегез белән котлыйбыз! Ирешелгәннәрдә генә тукталып калмаска, һәрчак алга барырга, теләсә нинди биеклекләрне яуларга телибез!
Айсылу Рамил кызы һәм Гүзәл Нургали кызы зона этабында районыбыз данын яклаячак. Аларга уңышлар телибез!



# “Һәр җирдә уңыш, һәр адымда алга!”




2024 нче елның 13 нче декабрендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының «Укучылар сарае» МБУ базасында «Сафта»хәрби-спорт уеннары узды. Районнан 24 команда җыелды (100 дән артык егет).
Арчаның 6 нчы мәктәбе данын «Арча фронты " командасы яклады. Алар:
1) Сәлахетдинов Булат – 8 «В» сыйныфы
2) Җамалиев Ильяр-8 «В» сыйныфы
3) Медведкова Анна-8 «В» сыйныфы
4) Габдулнурова Әдилә-8 «Б» сыйныфы
Команда нәтиҗәләре:
-ябык бинада ориентлашу дисциплинасы буенча 1 урын (алтын медальләр);
-электрон коралдан ату дисциплинасы буенча 3 урын (бронза медальләр).
Гомумкоманда зачеты буенча барлык сынауларда «Арча фронты» командасы 24 команда арасында 3 урынны алып, ярышларда бронза медальләр яулады.
Җитәкчесе: Сәйфетдинов Ришат Фәннур улы. Алга таба да уңышлар телибез! Без сезнең белән горурланабыз!



10 нчы декабрь көнне безнең мәктәптә Ватан Геройлары көненә багышланган күп төрле ярышлар үткәрелде.
8 нче сыйныф укучылары түбәндәге дисциплиналарда көч сынаштылар: калашников автоматын җыю һәм сүтү; беренче ярдәм күрсәтү һ. б.
Ярыш нәтиҗәләре:
8 “А”-3 нче урын
8 “Г”-3 нче урын
8 “В”-2 нче урын
8 “Б” – 1 нче урын
Мәктәбебез яшь армиячеләрен яхшы нәтиҗәләр белән котлыйбыз!

7 нче декабрь көнне Казан шәһәренең «Мир» кинотеатрында «Милли мультfest» республика балалар кинофестивале җиңүчеләрен бүләкләү тантанасы узды.Быел конкурсның оештыру комитетында 498 гариза теркәлгән. Әлеге кинофестивальгә татар телендә балалар өчен төшерелгән анимацион һәм кыска метражлы фильмнар кабул ителде. Конкурста 7-17 яшьлек балалар һәм иҗат коллективлары катнашты.Арча шәһәренең алтынчы номерлы урта мәктәбе укытучысы Сәйфетдинов Ришад Фәннур улы җитәкчелегендәге "Бәхетле балачак" телестудиясе төшергән "Сихри дәфтәр" фильмы 2 нче урынга лаек булды.Афәрин! Чын күңелдән котлыйбыз! Без сезнең белән горурланабыз!





16 нчы декабрь көнне Арчаның 6 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбендә 9 нчы сыйныфларның проект эшләрен яклау үтте.
Һәр проект мөстәкыйль тикшеренү күнекмәләрен (проблемаларны кую, мәгълүматны җыю һәм эшкәртү, экспериментлар үткәрү, алынган нәтиҗәләргә анализ ясау) эшләүгә юнәлтелгән, иҗади сәләтләрне һәм логик фикерләүне үстерүгә ярдәм итә.
Укучыларны проект эшчәнлегенә җәлеп итү-укучыларның төп белем бирү программасын үзләштерүнең планлаштырылган метапредметлы нәтиҗәләренә ирешүне тәэмин итә торган уку-укыту эшчәнлегенең мотивациясен һәм эффективлыгын арттыру юлларының берсе.


# "Кышкы шәһәрчек - 2025! "



"Безнең мәктәп Яңа елга әзерләнә! Барыбыз да бәйрәм рухын күтәбез. Укытучылар һәм укучылар бергәләп, мәктәпне матурлап, Яңа ел бәйрәме өчен күп төрле чаралар оештыралар. Гадәттәгечә, бездә күңелле уеннар, җырлар һәм биюләр белән күңел ачу көтелә. Яңа елда һәркемнең хыяллары тормышка ашсын, һәм безнең бердәмлегебез тагын да ныгысын. Яңа ел яңа мөмкинлекләр, яңа башлангычлар, һәм күңелле мизгелләр белән тулы булсын!



# *Кроссворд*




Горизонталь буенча:
1. Мин – Яңа ел символы,
Ямь-яшел кулмәктәнмен.
Уенчыклар әгәр элсәң
Купшыланып китәрмен. (Чыршы)

3. Көлдерәбез Яңа елда,
Бездән дә юк осталар.
Без көлке сиртмәсеннән,
Артист-юморескалар. (Клоуннар)

5. Яңа еллар туганда
Һәммәсе дә телиләр.
Кабул булсам әгәр дә
Шатланышып йөриләр. (Теләк)

7. Бүләкләр төяп килә ул,
Яңа ел саен безгә.
Сагынып көтеп алабыз
Сине без һәммәбез дә!
(Кыш Бабай)

Вертикаль буенча:
2. Чыршыларга эленәбез,
Сүнәбез дә, янабыз.
Яңа елны яратабыз,
Шуңа балкып торабыз. (Гирлянда)

4. Француз исеме белән бәйле
Яңа ел салаты буламын.
Тик Франциядә түгел шул,
Рәсәйдә популярмын! (Оливье)

6. Кыш Бабайның оныгы мин,
Аның белән гел бергә.
Тамаша кылып йөрибез
Яңа ел бәйрәмендә. (Карсылу)

8. Елга ул бер генә килә,
Һәркем дә аны көтә.
Тылсымга бай бәйрәм,
Биибез әйлән-бәйлән. (Яңа ел)

## Әкият

**“Марат һәм чуртан балыгы”**

Борын-борын заманда бер авылда яшәгән Марат исемле бер малай. Ул балык тотарга яраткан. Кышкы матур көннәрнең берсендә су буена юл тоткан. Әнисенә бәйрәм күчтәнәче ясау булган теләге. Шактый озак утыра торгач, Маратның кармагына тылсымлы чуртан эләккән. Ул Маратка: “Мине җибәрсәң, 3 теләгеңне үтим”,-дигән. Башта Марат үзенең табышын югалтырга теләмәгән. Ул бик акыллы егет булган, чуртанның, үзе укыган әкияттәге кебек, телгә килеп сөйләшүенә бик ышанып та җитмәгән. Шулай да Марат чуртанга теләкләрен җиткерергә булган. Беренче теләк итеп авыру балаларны тиз арада савыктора торган шифаханә сораган, икенче теләге - әтисе белән әнисенә матур өй, ә өченчесе үзенә телефон булган. Балык Маратның теләкләрен үтәргә сүз биргән. «Алга таба да акыллы бул, Марат!» - диеп китеп барган.

Марат безнең якында гына яши. Һичшиксез, аның барлык теләкләре дә үтәлер!

*Халитов Айзат, 5 нче В сыйныфы укучысы*



Мәктәп сайтына кереп, сез мәктәп тормышы турында мәгълүматлар белән тулырак итеп танышып чыга аласыз: